Мәгариф идарәсенең № 226 нчы боерыгы (23.03.2021)
нигезендә расланды

**Татарстан Республикасында**
**Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган**
**“Тел кешене дус итә ”шәһәр фестивале**
# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**Фестивальнең максатлары һәм бурычлары:**

**1**. Татар, рус, удмурт, мари халыкларының милли бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, милли ризыклары аша укучыларда, милли хәзинәбезне саклау, алар белән горурлана белү сыйфатлары тәрбияләү.

**2.**Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә иркәле куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү;

**3.**Сәләтле укучыларны барлау, үстерү һәм чыгышларын бәяләү**.**

**Катнашучылар:**

Бәйгедә Әгерҗешәһәре гомуми белем бирү учреждениеләренең 7-8 нче сыйныф укучылары, Әгерҗе шәһәре туган тел укытучылары катнаша.
**Бәйгенең теле**: татар теле

**Үткәрү вакыты һәм урыны:**
**22 апрель, 2021 ел ,**
Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиясе (Адрес: Әгерҗе шәһәре, Нариманов урамы, 27 йорт).

**Конкурсның шартлары:**
**1. “Дуслык белән көчле без”** Һәр мәктәп коллективы (5 укучы) бер милләтне татар телендә тәкъдим итә.(үзенчәлекләрен ача), 5 мин(өй эше);
( Гимназия мари халкын, 2нче мәктәп татар халкын, 3нче мәктәп рус халкын, 4нче мәктәп удмурт халкын тәкъдим итә)
**2. “Милли ризык – өстәл күрке”.** Милләтнең бүгенге көндә бренд ризыгы булмаган (онытылып баручы) бер ризыгына видеопрезентация+ әзер ризык (өй эше)
**3. “Матурлык сәхнәсе”. Заманча милли киемгә дефиле.**
**4**. **“Остаханә”** Милли киемгә аксессуар ясау(кирәкле әйберләрне һәр команда үзе алып килә)
**5. “Акыл ияләре”** Интеллектуаль уен

**6. Укытучылар өчен:**
“Китап киштәсе ни сөйли?” (түгәрәк өстәл). Соңгы вакытта нәшер ителгән әдәби әсәргә реклама. Тәкъдим ителә торган язучы, шагыйрьләр:
Айгөл Әхмәтгалиева – 3нче мәктәп.
Ркаил Зәйдулла – 4нче мәктәп.
Гөлүсә Батталова – 2нче мәктәп.
Рүзәл Мөхәммәтшин – 1нче гимназия.

**Бәйгене йомгаклау һәм нәтиҗә ясау**
Бәйге ахырында йомгак ясала, **к**онкурста катнашучыларга сертификатлар, җиңүчеләргә дипломнар тапшырыла.